

# Ачык дәресебез күңелле үтсен!

Татарларда иң кадерле кунакларга чәй янына таба ашы – *белен* (**коймак**) пешергәннәр.

Аның бит алмалары *алланган:* **әнис алма кебек булган**.

*Шигырьләрем* - **җан җимешем**,

Алыштырмам бернигә дә.

Бер шигырь дә язма имеш,

Яшә дә син шушы җирдә.

*("Минем бәхет". Диләрә Хуҗина.)*

Бик сагындым сине, бик сагындым,

*Бәләкәчем* - **сары кошчыгым**.

Бик сагындым сине, бик сагындым,

Сары чәчле нәни кызчыгым.

*(“Кызыма хат”. Диләрә Хуҗина.)*

Сагынып кайтам,

Киткән идем...

Әйтерсең лә кичә генә,

Балачагым яши *монда*,

**Биек тау итәгендә**.

*(“Туган авыл”. Диләрә Хуҗина.)*


Җөмлә кисәкләре
Ия
Хәбәр
Тәмамлык
Хәл
Аергыч
?


Җөмлә кисәкләре
Ия
Хәбәр
Тәмам-лык
Хәл
Аер-гыч
Анык-лагыч

1. Нәрсә ул а н ы к л а г ы ч?

2. Нәрсә ул а н ы к л а н м ы ш?

3. Аныклагыч аныкланмышка нинди чаралар ярдәмендә бәйләнә?

4. Аныклагыч башка иярчен кисәкләрдән кайсы ягы белән аерыла?

1. Җөмләдә ияртүче кисәктән соң килеп, аның мәгънәсенә өстәмә ачыклык, төгәллек кертә торган сүзләр - аныклагыч.

2. Аныклагыч белән ачыкланып килә торган җөмлә кисәге - аныкланмыш.

3. Аныклагыч аныкланмышка түбәндәге сүзләр белән бәйләнә:

- аныклау интонациясе.
- теркәгеч вазифасындагы сүзләр:

ягъни, икенче төрле әйткәндә, аеруча,җитмәсә, аерым алганда, шул исәптән, атап әйткәндә, бигрәк тә һ.б.

4. Аныклагыч башка иярчен кисәкләрдән ике ягы белән аерыла:

- ул һәрвакыт ияртүче сүздән соң килә.
- ияртүче сүзнең мәгънәсенә аныклык, төгәллек өсти.


**Аныклагычлар** янында тыныш билгеләре


Аныклагычлар янында тыныш билгеләре
,
—
:
( )

# Число

## Аныклагычлар янында тыныш билгеләре

138 нче күнегү

Бөек Тукай теле___________________________

*140 нчы күнегү*

1. *а*
2. *б*
3. *б*
4. *ә*
5. *б*

1) Атның аякларын кыздырып тормадым. 2) Хуҗасы үзе дә таякны тиз сындырырга ярата торган кеше икән.

3) Китә башлагач, атның иясе мине туктатып, колагыма тукыды:

— Кара аны, баш килерлек булмаса, хайванны юкка яндырма. 4) Җавабым юк, дөрес сүз.5) Булмастайны камчылаудан ни файда?

6) Тезелдек. 7) Башта бер - ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек дип әйтерлек. 8) Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. 9) Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады,.. тик шулай да ул берәүне дә куркытмый. 10) Мине ул түгел, арттан уйнаклап килүче теге кашка байтал шикләндерә. 11) Үз атымның чамасы үземдә, камчы тидерергә ашыкмыйм — бар нәрсәнең дә вакыты була бит…

12) Алда, берничә чакрым ераклыкта, колга башындагы сөлгеләр чагылып киттеләр. 13) Хәйлә бетте, безнең аяк астында хәзер җир, җитмәсә, тагын нинди җир! 14) Йә күтәрә ул, йә башыңны яра. 15) Уен түгел икәнлекне ат та сизенде: кинәт сикереп алды. 16) Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем — без хәзер аның белән тигез барабыз. 17) Госманга бу ошамады. 18) Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. 19) Күземә кинәт кан бәрелде,— күрә дә, уйлый да алмадым. 20) Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем. 21) Ул чайкалды, аты өстеннән очып төшеп калды...

22) Госманнан, тагын берничә ярканаттан җиңел генә узып китсәм дә, кашка байталдан узу ансат булмады.

23)Сөлгегә килеп җитәргә ярты чакрым чамасы җир калганда, мәйдандагы халыкның умарта корты төсле гөжләве ишетелә башлады. 24) Кемдер, ярсулы тавыш белән:

— Каула, Айдар! — дип кычкырып җибәрде.

25) Кауларга кирәк икәнен мин үзем дә бик яхшы белә идем, шулай да ул ярсулы тавыш ярап куйды, тартып алган төсле булды ул.

*Ф. Хөснидән.*

2 Татар сөйләменә хас ирен гармониясе чагылыш тапкан сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) *Атның аякларын кыздырып тормадым.*

2) *Булмастайны камчылаудан ни файда?*

3) *Уен түгел икәнлекне ат та сизенде: кинәт сикереп алды.*

4) *Җавабым юк, дөрес сүз.*

3 Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан, 1 – 4 нче җөмләләрдә фразеологик әйтелмәләр булган җөмләне арта бару тәртибендә күрсәтегез.

4 14 нче җөмләнең грамматик нигезен күчереп языгыз.

5 7 - 9 нчы җөмләдән чама санын табып язарга.

6 Сөйләмнең тәэсир көчен арттырыр өчен, 23 – 25 нче җөмләләрнең берсендә кире сүз тәртибе файдаланылган. Шул җөмләнең номерын языгыз.

7 10 -13 нче җөмләләрдә кулланылган алмашлыкларның санын язарга.

8 12 -17 нче җөмләләрдә аныклагычлар булганын арта бару тәртибендә санын язарга.

9 Сөйләмнең тәэсир көчен арттырыр өчен, 12 - 16 нчы җөмләләрнең берсендә кире сүз тәртибе файдаланылган. Шул җөмләнең номерын языгыз.

10 Текстта бирелгән сорау җөмләнең санын языгыз.

2 – 4

3 – 1, 2, 3

4 – ул күтәрә, яра

5 – бер – ике

6 – 25

7 – 7

8 – 12, 15

9 – 14

10 – 5

1. Дәрестә нинди уку мәсьәләсен тикшердек?

2. Билге кую.

3. Өй эше: 141 – 143 нче күнегүләр.